| МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО - КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ |
| --- | --- | --- |

№ ___1825/о_______

ПРИКАЗ БОЕРЫК

«__18___»______12________2025__

Татарстан Республикасы Норлат муниципаль районы Советының 19.12.2012 ел, № 200 карары белән расланган Татарстан Республикасы Норлат муниципаль районын территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр кертү турында

Рәсәй Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 19-21 статьялары, “Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында” 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы һәм “Шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында вәкаләтләрне яңадан бүлү турында” 2023 елның 23 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының” Татарстан Республикасы Норлат муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр кертү проектын әзерләү турында” 23.09.2025 ел, № 1366/о боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 15.12.2025 ел, № 10-53/15435 бәяләмәсен исәпкә алып, боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Норлат муниципаль районы Советының 19.12.2012 № 200 карары белән расланган Татарстан Республикасы Норлат муниципаль районы территориаль планлаштыру схемасына (Татарстан Республикасы Норлат муниципаль районы Советының 10.09.2013 № 256, 29.03.2019 №,210, 21.5.2020 № 281, 16.10.2020 №22, 22.09.2023 №,201, 15.12.2022 № 153, 07.08.2024 № 250, 15.11.2024 № 270 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1 өлештә "Территориаль планлаштыру турында Нигезләмә”:

“Норлат муниципаль районын территориаль планлаштыру буенча җирле (район) әһәмияттәге чаралар исемлеге” 1 бүлегенә әлеге Боерыкның 1 нче кушымтасы нигезендә “Калдыклар белән эш итү чаралары” 1.7 пункты өстәргә.;

әлеге боерыкка 2 нче кушымта нигезендә 1.7.1. таблицада күрсәтелгән “Татарстан Республикасы Норлат муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасы. Җирле әһәмияттәге объектларны планлаштырып урнаштыру картасы” картасы өстәргә.

2. Территорияләрне үстерү департаментының агломерацияләрне үстерү идарәсенең көньяк-көнбатыш районнарны үстерү бүлегенә (А. С. Харитоновка):

әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Норлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә ул үз көченә кергән көннән җиде календарь көннән дә соңга калмыйча җибәрү;

әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында ул үз көченә кергән көннән җиде календарь көннән дә соңга калмыйча урнаштыру;

әлеге боерыкны “Татарстан Республикасы шәһәр төзелеше эшчәнлеген мәгълүмати тәэмин итү” Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасында ул басылып чыккан көннән алып 10 эш көне эчендә урнаштыруны;

әлеге боерыкны территориаль планлаштыруның Федераль дәүләт мәгълүмат системасында ул басылып чыккан көннән алып 10 календарь көннән дә соңга калмыйча урнаштыру.

3. Юридик бүлеккә (Р.И. Кузьминга) әлеге боерыкны дәүләт теркәвенә алу өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрүне тәэмин итәргә.

4. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

5. Әлеге Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны территорияләрне үстерү департаментының агломерацияләрне үстерү идарәсе башлыгы С.А. Рыбаковка йөкләргә.

Министр урынбасары В.Н. Кудряшев

Отдел контроля исполнения документов

Татарстан Республикасы
Төзелеш, архитектура һәм
торак-коммуналь хуҗалыгы
министрлыгының 18.12.2025 №
1825/о боерыгына 1 нче
кушымта

## 1.7. Калдыклар белән эш итү гамәлләре

1.7.1 нче таблица

### Муниципаль районның җирле әһәмияттәге калдыклар белән эш итү буенча урнаштыру өчен планлаштырыла торган объектларның төрләре, билгеләнеше һәм исемнәре турында белешмәләр, аларның төп характеристикалары, урнашу урыны, шулай ук территорияләрдән файдалануның махсус шартлары булган зоналарга характеристикалар, әгәр шушы объектларны урнаштыруга бәйле рәвештә мондый зоналарны билгеләү таләп ителсә

| № | Урнашу урыны | Объект исеме | Объектның билгеләнеше | Объектның статусы | Объектка характеристика | Гамәлгә ашыру срогы | Территорияләрдән файдалануның махсус шартлары булган зона |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Урта Камышлы авыл җирлеге, 16:32:070706:822 җир кишәрлеге | Чүп-чарны күчерү станциясе | КККны беренчел эшкәртү өчен шартлар тудыру | Урнаштыру планлаштырыла торган | 0,6500 га | 2026 | Санитар-яклау зонасы - 100 метр (7.1 СанПин таблицасының 12.4.8 пункты) 2.2.1/2.1.1.1200-03 “Предприятиеләрнең, корылмаларның һәм башка объектларның санитар-яклау зоналары һәм санитар классификациясе”) |

Искәрмәләр:

- объектның мәйданы якынча һәм проектлауның алдагы стадияләрендә үзгәрергә мөмкин;
- Калдыклар белән эш итү объектларын урнаштыру чараларын табигатьне саклау һәм санитария-эпидемиология законнары нормаларын һәм таләпләрен үтәү, шул исәптән Рәсәй Федерациясе Хөкүмәтенең 2018 елның 3 мартындагы № 222, һәм СанПиН 2.2.1/2.1.1.1200-03 “Предприятиеләрнең, корылмаларның һәм башка объектларның санитар-яклау зоналары һәм санитар классификациясе” карары белән расланган санитария-яклау зоналарын билгеләү һәм санитария-яклау зоналары чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләреннән файдалану кагыйдәләре таләпләре нигезендә якындагы нормалаштырыла торган объектларны исәпкә алып санитария-

яклау зоналарын оештыру шартларында гына гамәлгә ашырырга мөмкин.

– торак пунктлар чикләреннән читтә урнашкан һәм файдалы казылмалар яткан мәйданнарда урнашкан җир кишәрлекләрен төзү бары тик җир асты байлыкларының дәүләт фонды белән идарә итүнең федераль органы яисә аның территориаль органы рөхсәтен алганнан соң гына рөхсәт ителә (“Җир асты байлыклары турында” 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 номерлы Рәсәй Федерациясе Законының 25 статьясы).

Татарстан Республикасы
Төзелеш, архитектура һәм

